**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№849**
**25.02.2020**

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә муниципаль торак контролен гамәлгә ашыру буенча муниципаль функцияне үтәүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясе Торак кодексына үзгәрешләр кертү турында» 2019 елның 2 декабрендәге 390-ФЗ номерлы Федераль закон, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24 пункты нигезендә

К А Р А Р   Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның 2018 елның 27 мартындагы 1631 номерлы карары (Башкарма комитетның 2018 елның 10 июлендәге 3844 номерлы, 2018 елның 24 июлендәге 4158 номерлы, 2019 елның 6 февралендәге 556 номерлы, 2019 елның 8 маендагы 2396 номерлы карарлары редакциясендә) белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә муниципаль торак контролен гамәлгә ашыру буенча муниципаль функцияне үтәүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- 2.5.1 пунктның дүртенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «1) күпфатирлы йортлар белән идарә итү эшчәнлеген гамәлгә ашыра башлау турында дәүләт торак күзәтчелеге органына тапшырылган белдерү кәгазе нигезендә торак милекчеләре ширкәте, торак, торак-төзелеш кооперативы яки башка махсуслаштырылган кулланучылар кооперативы тарафыннан әлеге эшчәнлекне гамәлгә ашыра башлаудан соң;».

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» газеталарында рәсми бастырып чыгаруны, «Интернет» челтәрендә ТР рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) һәм шәһәрнең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет Җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручы                                                  И.С. Зуев